ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НИЖНЕУСЛОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Заводская, д.55, с. Нижний Услон, 422574

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ТҮБӘН ОСЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Завод ур., 55 нче йорт, Түбән Ослан авылы, 422574

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

16.12.2024 — 218

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48

с. Нижний Услон

Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Уставы нигезендә, Түбән Ослан авыл җирлегенең Түбән Ослан авылы территориясендә 2024 нче елның 05 нче декабрендәге 1,2,5 нче номерлы гражданнар җыенында кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатында Түбән Ослан авыл җирлеге Башкарма комитеты карар чыгарды:

1. Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан авыл җирлегендә гражданнарга үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районының
Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы — А. В. Архиреев

Түбән Ослан авыл
җирлеге Башкарма
комитетының
16.12. 2024 ел № 218
карарына
1нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым җыю тәртибе

1. Әлеге Тәртип Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан авыл җирлегендә гражданнарга үзара салым акчасын җыю кагыйдәләрен билгели

2. Гражданнарның үзара салым акчалары 2025 елның 01 гыйнварыннан 2025 елның 31 мартына кадәр Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең Түбән Ослан авылындагы Степан Разин, Ленин, Чернышевский урамнары, Красноармейская урамында 49 нчы йорттан 49 нчы йортка кадәр теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан, гражданнар җыенында катнашуларына һәм тавыш биргәндә алар белдергән мөнәсәбәтләренә карамастан, түләнә.

3. Түләүләр күләме түбәндәге категория гражданнар өчен гражданнар җыены турындагы карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә:

а) күпбалалы гаиләләр,

б) уку йортлары студентлары,

в) тыл хезмәтчәннәре

г) СВО катнашучылары һәм аларның гаилә әгъзалары.

5. Бер мәртәбә бирелә торган түләү турында хәбәрнамә (хәбәр итү) бланкы почта элемтәсе аша юллама бирү юлы белән гражданнарга җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (хәбәр итү) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә.

7. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясарга, почта күчерүләрен башкарырга хокуклы оешмалар (исәп-хисап оешмалары) аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша https://uslugi.tatarstan.ru/.сылтамасы буенча акча күчерү юлы белән башкарыла.

8. Түләү фактын раслау булып керем касса ордеры квитанциясе, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслый торган башка документлар тора.

9. Билгеләнгән срокта кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Югары Ослан
муниципаль районы
Түбән Ослан авыл
җирлеге Башкарма
комитетының
16.12. 2024 ел № 218
карарына
2нче кушымта

ХӘБӘРНАМӘ (ХӘБӘР) № _______________
Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер мәртәбә түләнә торган түләү турында

Түләүченең Ф. И.А. и. _________________________
Адрес: ____________________________________________________________
_________________________________________________________ нигезендә
Сезгә _______________________ вакытына кадәр
__________________________________________________ чараларны тормышка ашыру өчен _____________ сум күләмендә,
түбәндәге реквизитлар буенча:
_________________________________________________ бер тапкыр акча түләргә кирәк.
Алучының банк БИК _____________________________________
Сч. № _________________________________
Алучының сч. №__ . ________________________________________
ИНН _________________________________________
КПП _________________________________________
КБК _______________ ОКАТО__________________
Түләүне билгеләү
____________________________________________________________________

Җитәкче _________________ _______________________________________
М. у. (имза) (имзаны киңәйтеп язу)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәрнамә (Хәбәр) № _________________
бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында ______________________
(муниципаль берәмлек исеме)
________________ сум күләмендә.
Түләүченең Ф. И.А.и. ______________________________________________________
Адрес:
________________________________________________________________________
Алдым «__» _________________ 20___ ел. _____________________________
(түләүченең имзасы)
*Искәрмә. Әгәр дә хәбәр түләүчегә шәхсән бирелсә, аермалы төпсәсе тутырыла һәм _______________ авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.*